Республика Татарстан
Глава
Какре-Елгинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Кәкре Елга авыл җирлеге
башлыгы

ул. Советская, д. 22, село Какре-Елга,
Азнакаевский район, 423320

Совет урамы, 22 нче йорт, Кәкре Елга авылы,
Азнакай районы, 423320

Тел. (факс) 8(85592) 37-0-47; e-mail: Kelg.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» март 2021 ел №1

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының «Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең 2020 ел өчен бюджет үтәлеше турында»гы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге халкының Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының«Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең 2020 ел өчен бюджет үтәлеше турында»гы карары проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» дип исемләнгән 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә, халык алдында тыңлаулар үткәрү юлы белән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20нче статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының 2012 елның 19 апрелендәге 37 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә таянып, **карар итәм**:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының «Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең 2020 ел өчен бюджет үтәлеше турында»гы карары проекты (1нче кушымта) буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2.Халык тыңлауларын үткәрү инициаторы булып Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы тора.

3.Билгеләү:
- уздыру вакыты - 2021 елның 08 апреле 10.00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны – Кәкре Елга авылы мәдәният йорты;
- әлеге мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул ителә торган адрес: 423320, ТР, Азнакай районы, Кәкре Елга авылы, Совет урамы, 22.

4.Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының «Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең 2020 ел өчен бюджет үтәлеше турында»гы карары проекты буенча гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карар нигезендә билгеләнгән срокларда тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

5.Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Советының «Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең 2020 ел өчен бюджет үтәлеше турында»гы карары проектын (1нче кушымта) 2021 елның 17 мартыннан да соңга калмыйча Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

Башлык И.М.Мөхәмәтҗанов